ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

11.10.2021 с.Старое Дрожжаное №437

2022 елга Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында сәнгать-эстетик юнәлештә өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы балаларга сәнгать-эстетик юнәлештә өстәмә белем бирү учреждениеләрен норматив финанслауны кертү турында» 2009 елның 14 декабрендәге 854 номерлы карары һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2022 елга расларга:

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында сәнгать-эстетик юнәлештә өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә кушымта итеп бирелә торган норматив чыгымнар;

балаларга сәнгать-эстетик юнәлешле өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарга карата төзәтү коэффициентын 0,5 күләмендә расларга.

2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына әлеге карарның 1 пунктында расланган норматив чыгымнар нигезендә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ башлыгы И.А. Халитовка йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе Д.А. Сатдинов

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль
районы Башкарма комитетының карары белән
расланган «11» 10 2021 № 437

**Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының балаларга өстәмә белем бирү оешмаларында сәнгать-эстетик юнәлештә өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең**

**НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАРЫ**

| Өстәмә белем бирү программасының юнәлеше | Территориаль урнашуы | Норматив чыгымнар (1 укучыга елына, сумнарда) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | өч еллык уку вакыты | дүрт еллык уку вакыты | биш еллык уку вакыты | җиде еллык уку вакыты | иртә һөнәри юнәлеш бирү |
| Музыка сәнгате | авыл җирлеге | | | 60 519 | 70 105 | 90 982 |
| Рәсем сәнгате | авыл җирлеге | | 33 235 | | 28 980 | 69 559 |
| Хореография сәнгате | авыл җирлеге | | | 63 795 | 52 609 | 191 884 |
| Гомуми эстетик сәнгать | авыл җирлеге | | | 27 818 | | |
| Фольклор сәнгате | авыл җирлеге | | | 60 079 | 57 660 | 93 239 |
| Эстрада-джаз сәнгате | авыл җирлеге | 92 265 | | 88 340 | | 145 742 |
| Театр сәнгате | авыл җирлеге | 47 585 | | 44 206 | 44 213 | 69 610 |

Эшләр белән идарә итүче: Сабир Д.Р. Сабирҗанова